## БЕЗНЕҢ ИНТЕРВЬЮ

# ТЕМПНЫ СҮРЕЛДЕРМИЧӘ

**«Рассвет» совхозы бүгенге көндә иң эре хуҗалыкларның берсе. Басудан даими югары уңыш алуы, терлекчелек продукциясе җитештерүнең стабильлеге белән аерылып тора совхоз. Тотрыклы үсеш алдагы көнгә карап эшләүдән, киләсе көн турында бүгеннән кайгыртудан килә. Хуҗалыкта шулай эшлиләр. Совхоз директоры Х.Н.Атауллин белән әңгәмәбез хуҗалык игенчеләре һәм терлекчеләренең бүгенге хезмәте хакында.**

**КОРР.** **Харис Нуруллович, бүген 1 нче декабрь. Сез аны нинди мәшәкатьләр белән каршыладыгыз?**

**Х. Н. А.** Авыл кешесенең, билгеле инде, мәшәкате кайчан бетеп торганы бар. Бер төрлеләреннән арынган гына буласың, икенчесе көтеп тора.

Һәр тармакта да көндәлек эшләр җитәрлек.

**КОРР. Быел сезнең совхоз һәр гектардан 30 центнердан артык уңыш алды. Бу үрдән чикмәссезме? Шулай икән, бу юнәлештә бүген күрелә торган чаралар турында беркадәр сөйләп үтсәгез иде.**

**Х. Н. А.** Алдан шуны әйтим, бу максатка без күп еллар дәвамында килдек. Уңышны күтәрү өчен эш берничә юнәлештә алып барылды. Мул уңыш бирүче югары репродукцияле орлык чәчү, игенчеләрнең һәр агрочараны сыйфатлы һәм кулай срокларда башкаруы максатка алып килде.

Бу хакта сөйләгәндә тагын бер факторга аерым басым ясап үтәсем килә, ул — җирләрне ашлау. Ашлаган җир аш бирә, дип тикмәгә генә әйтмиләр бит. Соңгы елларда басуларга ашламаны мул кертәбез. Минераль һәм органигын да. Быелның унбер аенда, мәсәлән, кырларга 52 мең тоннадан артык черемә чыгарылды. Бу — сөрү җирләренең һәр гектарына бүлгәндә уртача 10 тоннадан артык туры килә дигән сүз. Сүз уңаеннан әйткәндә, бу эштән бүген дә туктаганыбыз юк. Киләсе елда да уңышны мул үстерү өчен төп алшартларның берсе шуннан гыйбарәт.

**КОРР. Язга хәзерлек буенча эшләрегез ничегрәк тора?**

**Х. Н. А.** Аны көздән үк башлаган идек. Такычларны, катокларны механизаторларыбыз кыш кергәнче үк төзәтеп, саклауга куеп калдырдылар.

Хәзер техника паркларында эшнең кызу чагы. Яңа елга кадәр басуда файдаланыла торган барлык төр тагылма машиналарны ремонтлауны төгәлләү бурычы куйган идек.

Беренче бүлекчәдә Габдулла Галиуллин һәм Әхтәм Хөсәенов тырмаларны тәртипкә китерү белән мәшгульләр. Культиваторларны исә Мингата Мостафин, чәчкечләрне Нурвахит Манәпов белән Минзәки Габдуллин төзәтә. Аларның һәркайсы үзенә йөкләтелгән вазифаны күңел биреп башкара.

Икенче бүлекчәдә дә шул ук тәртиптә төзелгән махсус звенолар тагылма механизмнарны сафка бастыруда хезмәт куя. Геннадий Крайнов, Николай Максимов, Ильяс Фәйзуллин, Галимҗан Гайнуллин, Олег Вәлитов тырма, культиватор ише инвентарьны язга хәстәрлиләр. Хәмит Низаметдинов, Исхак Фәйзуллин һәм Равил Вәлиев исә чәчкечләрне язын төгәл эшләрлек хәлгә китереп кую өчен бүген үк чарасын күрәләр.

Өченче бүлекчә игенчеләре дә озакламый яз киләсен онытмыйлар, күршеләре алдында сынатмаска, йөзләренә кызыллык китермәскә тырышалар.

Бер үк вакытта башка төр техниканы язга көйләп кую да онытылмый. Тракторлар, комбайннар һәм башка төр агрегатларны да көйләү бара. Һәр эшче заманага карап күңелен боектырмый, алдагы көн турында уйлана, киләчәккә өмет белән карап яши.

**КОРР. Харис Нуруллович, кыш терлекчеләр өчен катлаулы, кыен чор. Аны ничек кичерәсез?**

**Х. Н. А.** Бу мәсьәләдә сезнең фикер белән килешәм, терлекчеләр өчен үтә җаваплы этап ул кыш. Аңа ныклы хәзерлек белән кердек. Мал азыгы — саламы, печәне, силосы һәм сенажы — кышны тыныч үткәрерлек күләмдә хәзерләп куелган иде. Уңыш, алда әйткәнебезчә, югары булды, шуңа күрә фураж максатларына бәртекле ашлыкны да җитәрлек күләмдә туплап калдырдык. Катнаш азык малларга пешереп кенә бирелә. Мондый азыкны терлекләр яратып та ашый, туклыклылыгы ягыннан да файдалы.

**КОРР. Ел төгәлләнеп килә инде. Дәүләт алдындагы заказларны үтәү өчен эшләр ничек тора?**

**Х. Н. А.** Ул яктан совхоз эшчеләренең күңеле күтәренке, йөзләре ак. Хуҗалык еллык заказ буенча дәүләткә 15400 центнер сөт тапшырырга тиеш булса, индивидуаль секторны да кертеп, 1 декабрьгә аны 16911 центнер күләмендә озаттык, ягъни задание 110 процент итеп башкарылды.

Ит буенча дәүләт заказыбыз 3400 центнер күләмендә иде. Бүгенге көнтә ул 3439 центнер хәзерләнде. Йон тапшыру заданиесен җәен үк үтәгән идек инде.

**КОРР. Мәгълүм ки, үткән ел сезнең совхоз социаль программаны гамәлгә ашыру буенча күп эш башкарган иде.**

**Х. Н. А.** Замананың авыр булуына карамастан, мәсьәлә көн тәртибеннән төшкәне юк. Индивидуаль йорт салучыларга материаллар, транспорт белән дә ярдәм итәбез. Авылга газ кертү буенча махсус звено эшли. Аның составында Рәфис Бикиниев, Илгиз Хөсәенов, Минсәлим Галимов һәм башкалар хезмәт куя. Димитровград шәһәреннән килгән монтажчылар белән берлектә алар авыл эчендә газ линияләре сузалар, башка хәзерлек чаралары күрәләр.

Тормышыбызда кискен борылыш елы булган 1992 ел төгәлләнеп килә. Совхоз эшчеләре производствода, тормыш-көнкүрешендә кыенлыкларны сизеп, һәрдаим татып яшәсәләр дә, күңелләрен сүрелдермиләр, хезмәтләренең нәтиҗәлелеген киметми эшләп төгәлләп киләләр елны. Бүгенге көндә анысы гаять мөһим.

**Әңгәмәне газета корреспонденты Р. АЙЗАТУЛЛИН оештырды.**

## Кем ничек эшли?

**Индивидуаль сектордан сөт җыю барышы.**

Беренче багана — авыл Советлары, икенче — сөт тапшыру буенча җиткерелгән еллык план (центнерларда), өченче — 11 айда бер сыердан тапшырылган сөт, дүртенче — узган елның шул чоры белән чагыштырганда артык яки ким (килограммнарда).

| | | | |
|---|---|---|---|
| Андреевка | 505 | 145 | +29 |
| Богдашкино | 501 | 334,3 | +34,3 |
| Киекле | 2050 | 193,5 | —58,5 |
| Иске Чаллы | 1694 | 137,8 | —233,2 |
| Яңа Иглай | 1464 | 605,9 | +90,9 |
| Кормыш | 2274 | 755,4 | —12,6 |
| Урта Камышлы | 986 | 224,3 | —107,7 |
| Егоркино | 1373 | 399,2 | +136,2 |
| Якушкино | 1089 | 220,3 | +32,3 |
| Биләр Озеро | 1050 | 119,3 | +42,3 |
| Бикүле | 1933 | 108,1 | —54,9 |
| Аксумла | 1282 | 204,2 | —126,8 |
| Фома | 1614 | 425,8 | —67,2 |
| Мамык | 636 | 140,4 | —52,6 |
| Сәләнгеш | 752 | 289,6 | —12,4 |
| Елаур | 1188 | 50,6 | —12,4 |
| Тимерлек | 640 | 124,5 | —62,5 |
| Иске Әлмәт | 1050 | 350,9 | +34,9 |
| Кычытканлы | 897 | 712,4 | +26,4 |
| Әмзә | 860 | 380,9 | —57,1 |
| Колбай Мораса | 1131 | 222,8 | —49,2 |
| Заречный | | 28,0 | +5,0 |
| Төрнәс | 744 | 192,5 | +85,5 |
| Чулпан | 1287 | 322,5 | +100,5 |
| Югары Норлат | | 474,2 | —456,8 |
| Район буенча | 27000 | 291,3 | —27,8 |

— Бөтен бригада аларга карый, — диделәр «Путь к коммунизму» колхозында слесарьлар Виктор Александрович Колесников, Владимир Прокопьевич Карпов, Владимир Юрьевич Сибулатов (рәсемдә) турында. Алтын куллы, һәр заказны җиренә җиткереп башкарырга гадәтләнгән слесарьларга кышкы чорда тагы да эш күбәя. Хәзер алар ремонт бригадасы составында авыл хуҗалыгы техникасын киләсе ел кыр эшләренә әзерлиләр, аны сыйфатлы итеп көйләү өчен көчләрен кызганмыйлар.



### ЯХШЫ СҮЗ — ҖАН АЗЫГЫ

Кадерле редакция! Мин язарга оста түгел, шуңа да ничек булдыра алганча язам. Минем кибетчебез Наталья Владимировна Казанкова турында сөйлисем килә. Ул яшь, энергияле, мөлаем, иң мөһиме үз сүзенә хуҗа була белә.

Мин инде пенсиядә. Радиоалгычым сафтан чыкты һәм мин Наталья Владимировнага мөрәҗәгать иттем. Таба алса, миңа радиоалгыч алып кайтуын сорадым. Ул вәгъдә бирде һәм бераз вакыттан соң, чыннан да аны миңа алып та кайтты.

Әйбере түгел, аның игътибары кадерле миңа.

**С. МИХАЙЛОВА.**
Яңа Тумба.

# 1993 ел календаре

Һәр мөселман өенең диярлек түренә эленгән календарь ел беткәнне генә искәртми. Аның һәр бите милли хисләребезне көчәйтә, милли горурлыгыбызны арттыра. 1993 ел өчен чыгарылачак календарьда бу юнәлеш бигрәк тә нык сизелә: мөселман айларының башлану көннәре, дини бәйрәмнәр, мәчет-мәдрәсәләр тарихлары, борынгыдан килгән гореф-гадәтләребез, йолалар, аш-сулар, үзебезнең төбәкләрдә үсә торган шифалы үләннәр, аларны файдалану ысуллары.

Әнә шуңа күрә аны Татарстанда яшәүчеләр генә түгел. Рәсәйнең төрле төбәкләрендәге милләттәшләребез дә сорап эзләтеп алалар. Аны табу хәстәренә болай бик иртә тотынуның сәбәбе — җиде миллион татар өчен чыгарыла торган бердәнбер календарьның тиражы 300 меңнән артканы юк. Ә 1993 ел өчен ул 250 мең генә данә булачак. Бу — календарь бастыру өчен нәшрият акча кызгана дигән сүз түгел. Безгә тиражның күләмен Татарстан китап сәүдәсе оешмасы һәм Татарстан кулланучылар берләшмәсе (Татпотребсоюз 1993 елга 80 меңгә генә заявка бирде. Республикабыз авыллары өчен бу тираж җитәр микән соң?) билгели. Әйтик, китап сәүдәсе 1993 ел өчен нибары 70 данә календарь таратырга ризалык бирде. Татарстан шәһәрләрен һәм Рәсәйдәге татарлар яши торган өлкәләрне татар басмалары белән тәэмин итүче бу оешма өчен, әлбәттә, мондый күләм белән чикләнү һич урынлы түгел. Бәлки бу очракта алар гаепле дә түгелләрдер. Әйтик, Пермь, Ульяновск, Оренбург, Төмән, Н. Новгород, Пенза, Мәскәү өлкәләреннән аларга заявкаларны я бик аз тираж белән бирәләр, я бу өлкәләрнең сәүдә системасы хезмәткәрләре үзләрендә яшәүче татарлар турында бөтенләй оныталар.

Әлбәттә, Татарстан китап нәшрияты шәхси үтенечләрне канәгатьләндерә алмый. Шулай да 1993 ел өчен нәшрият, бу ике оешма заявкасыннан тыш, тагын 95 мең данә календарь бастырып чыгара. Һәм аны халыкка сатуны да (гәрчә бу эш аның вазифасына кермәсә дә) үз өстенә ала. Моннан тыш, бу календарь сатуга бөтенләй кайтмаган авыллар өчен шундый киңәш тәкъдим итәбез: теләүчеләрдән акча җыеп, авылдан 1—2 кешене Казанга нәшриятка календарь алырга җибәрергә мөмкин. Әлбәттә, юл чыгымнары да авыл кешеләре өстеннән булачак. (Безнең адрес: 420111, Казан, Бауман урамы, 19, Матбугат йорты, Татарстан китап нәшрияты).

Календарьның басылып чыгу һәм сатыла башлау датасын без шушы газета аша өстәмә хәбәр итәчәкбез. Бу белешмәне тагын телефон (32—66—07) аша да сорый аласыз.

